| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2024 елның 20 марты — Иске Куак — № 1

Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыенының 2023 елның 18 ноябрендәге 1 нче, 2нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге Иске Куак торак пунктында 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 1 апреленә 16 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү һәм алынган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтерү белән килешәсезме:

1) ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

2) торак пункт территориясен төзекләндерү;

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н.Сушкова